ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.04.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 774**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2019/2020 елгы җылыту чорын тәмамлау һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 1891 номерлы «2019/2020 елгы җылыту сезоны башлану турында » карарын үз көчен югалткан дип тану турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2006 елның 17 мартындагы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы нормативтан югарырак (+8°С) булуга бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Төрле билгеләнештәге биналарны җылылык белән тәэмин итүче предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2020 елның 2 маенда Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җылылык чорын тәмамларга тәкъдим итәргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 1891 номерлы «2019/2020 елгы җылыту сезоны башлану турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Җылылык буенча хезмәт күрсәтүче предприятиеләргә, тышкы һава температурасы кискен төшкән очракта, биналар һәм торак биналар эчендә җылылык белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтүче инженерлык челтәрләренә җылылык җибәрүне көздә тотарга.
4. Әлеге карарны ЗМР Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат

сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) , «Зеленый Дол» һәм «Яшел Үзән» басмаларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче М.П. Афанасьев